**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«17» август 2026 ел № 32

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 18 июлендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 июлендәге 85 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2019 елның 25 октябрендәге 89 номерлы, 2020 елның 21 февралендәге 100 номерлы, 2023 елның 23 августындагы 58 номерлы, 2024 елның 20 июнендәге 78 номерлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 84 номерлы, 2024 елның 27 ноябрендәге 86 номерлы, 2026 елның 4 июнендәге 27 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 бүлектә:

21.4 пунктында «әлеге статья нигезендә» сүзләрен «әлеге бүлек нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

21.5 пунктында «әлеге статья нигезендә» сүзләрен «әлеге бүлек нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

21.6 пунктында «әлеге статья нигезендә» сүзләрен «әлеге бүлек нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

21.13 пунктта «әлеге Федераль закон,» сүзләрен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон,» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында. https://pravo.tatarstan.ru/ һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге
Советы рәисе Х.Х. Хәмидуллин